| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО СОЦИАЛЬНО-<br>ЭКОНОМИЧЕСКОМУ<br>МОНИТОРИНГУ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ<br>МОНИТОРИНГ<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.10.2017 г. Казань N №47-ос

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 6 статьясындагы 2.1 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының (алга таба – Комитет) һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Комитетның һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау Комитетның һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның карарлары закон көченә кергән көннән 10 көннән дә соңга калмыйча составы раслана торган эш төркеме тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны О.Ю.Семеновга йөкләргә.

Рәис В.П.Кандилов

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 2018 елның «1» октябрендәге № 47-ос боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының (алга таба – Комитет) һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен (алга таба – хокук куллану гамәлияте мәсьәләләре) карау процедурасын билгели, шулай ук Комитетның һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауны) законсыз дип тану турында судларның, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары (алга таба – суд карарлары) нәтиҗәләре буенча хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау буенча эш төркемен (алга таба – эш төркеме) формалаштыру мәсьәләләрен, эш төркеме утырышларын уздыру һәм мондый утырышларның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен җайга сала.

## II. Эш төркемен формалаштыру һәм аның эше тәртибе

2.1. Эш төркеме 8 кешедән эш төркеме рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм әгъзалары составында төзелә.

Эш төркеме составына Комитетта коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат кертелә.

Эш төркеме составына Комитетның суд тарафыннан гамәлдә булмавы танылган акт, карар проектын әзерләүдә, шулай ук килештерүдә һәм гамәлләр

кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан структур бүлекчәләре хезмәткәрләре кертелә алмый,

2.2. Эш төркеме үз эшчәнлеген утырышта башкара, утырыш суд карары үз көченә керү турында мәгълүмат кергән көннән 14 эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла.

Эш төркеме утырышына түбәндәгеләр чакырыла:

Комитетның суд тарафыннан гамәлдә булмавы танылган акт, карары проектын әзерләүдә, шулай ук килештерүдә һәм гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан структур бүлекчәләре хезмәткәрләре (алга таба – бүтән хезмәткәрләр) каралучы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү өчен;

акт, карар, гамәлләр (гамәл кылмау) нәтиҗәсендә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган затлар яисә аларның вәкилләре (алга таба – бүтән затлар);

түбәндәгеләрнең вәкиле (вәкилләре):

иҗтимагый оешма(ларның) (иҗтимагый оешма Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдиме буенча билгеләнергә мөмкин);

Татарстан Республикасы Прокуратурасы.

Эш төркеме рәисе эш төркеме утырышын уздыру датасын билгели.

Эш төркеме секретаре:

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына (Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тәкъдиме буенча иҗтимагый оешма вәкилләре чакырылган очракта) һәм Татарстан Республикасы Прокуратурасына вәкилләр кандидатуралары турында сорап гарызнамә җибәрә;

эш төркеме әгъзаларына, шулай ук утырышка чакырылучы затларга һәм вәкилләргә эш төркеме утырышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә.

2.3. Утырыш көненә ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Комитетның юридик секторы мөдире суд карарының үз көченә керүе турындагы белешмәне, мондый карарның күчермәсе белән бергә, эш төркеме рәисенә җибәрә.

Белешмәдә түбәндәгеләргә карата позиция булырга тиеш:

Комитетның һәм аның вазыйфаи затларының суд тарафыннан гамәлдә булмавы (законсыз дип) танылган норматив булмаган хокукый актны бастырып чыгару, каралар кабул итү һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау) нигезләренә;

Комитетның һәм аның вазыйфаи затларының норматив булмаган хокукый актларының гамәлдә булмавын, карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип тану нигезләренә.

2.4. Эш төркеме утырышы, анда эш төркеме составының яртысыннан артыграгы катнашса, тулы хокуклы була Утырыш рәис тарафыннан уздырыла, ә ул булмаганда – эш төркеме рәисе урынбасары тарафыннан.

2.5. Эш төркеме хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау барышында:

түбәндәгеләрне ачыклый :

суд тарафыннан гамәлдә булмавы (законсыз дип) танылган норматив булмаган хокукый актны бастырып чыгару, карарлар кабул итү һәм гамәлләр кылу (гамәл кылмау) мотивлары һәм хәлләре;

суд тарафыннан гамәлдә булмавы (законсыз дип) танылган норматив булмаган хокукый актның, карарның проектларын әзерләүдә, шулай ук гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан затларның гамәлләрендә коррупцион билгеләр булуны (булмауны), шул исәптән:

суд тарафыннан гамәлдә булмавы (законсыз дип) танылган норматив булмаган хокукый актның, карарның проектларын әзерләүдә, шулай ук гамәлләр кылуда (гамәл кылмауда) катнашкан затларның шәхси кызыксынуы хәлләрен (мәнфәгатьләр конфликты ситуацияләрен);

акт бастырып чыгару, карар кабул итү, гамәлләр кылу (гамәл кылмау) белән кызыксынучы затларның коррупцион тыкшынулары очраклары турында мондый затларның хәбәр итмәүләре хакында таныклаучы хәлләрне;

законнарга туры килми торган хокукый актлар бастырып чыгаруны, шулай ук карарлар кабул итүне һәм гамәлләр кылуны (гамәл кылмауны) һәм коррупцион күренешләрне кисәтүгә юнәлгән чаралар турында тәкъдимнәр әзерли.

2.6. Хокук куллану гамәлияте мәсьәләләрен карау йомгаклары буенча эш төркеме карар кабул итә, анда коррупцион күренешләр билгеләре булу (булмау) билгеләнә, шулай ук законнарга каршы килерлек норматив булмаган хокукый актлар бастырып чыгаруны, карарлар кабул итүне, гамәлләр кылуны (гамәл кылмауны), шулай ук коррупцион күренешләрне (мондый билгеләр булганда) кисәтү максатларында чаралар әзерләү һәм күрү буенча тәкъдимнәр бирелә.

Норматив булмаган хокукый акт бастырып чыгару, карарлар кабул итү, гамәл кылу (гамәл кылмау) мәнфәгатьләр конфликты ситуациясе булуны күз алдына китерерлек хәлләр ачыкланган очракта, барлык материаллар да Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе рәисенә тапшырыла.

2.7. Эш төркеме карары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

2.8. Утырыш йомгаклары буенча беркетмә төзелә, аңа секретарь һәм утырышта рәислек итүче имза сала. Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

утырышта катнашкан эш төркеме әгъзалары;

бүтән хезмәткәрләр;

утырышта чыгыш ясаганнарның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм чыгышларының төп тезислары;

тавыш бирү нәтиҗәләре;

кабул ителгән карар.

Беркетмәгә суд карары, суд тарафыннан гамәлдә булмавы танылган норматив булмаган акт күчермәләре, шулай ук каралучы мәсьәлә буенча бүтән материаллар кушып куела.

Утырыш беркетмәсе һәм суд карары Комитетның рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырыла.

2.9. Эш төркеме рәисе, утырыш уздырылган көннән 5 көннән дә соңга калмыйча, беркетмәне тиешле карарлар кабул итү өчен Комитет рәисенә җибәрә.